**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында» 2023 елның 13 июнендәге 399 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәнең 6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«и) Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, «Белешмәләр БК» махсус программа тәэминатын кулланып тутырылган белешмә формасында Татарстан Республикасы Рәисенә бирелә торган түбәндәге белешмәләрне кабул итү:

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъва кылган гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче гражданнар, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне;»;

б) «л» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

л) түбәндәгеләрне тикшерү:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелгән керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның коррупциягә каршы көрәшү максатларында кертелгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвен;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның коррупциягә каршы көрәшү максатларында кертелгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвен;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң федераль законнарда каралган очракларда хезмәт

шартнамәсе һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсе төзегәндә чикләүләрне үтәүләрен;

муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;»;

в) «о» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң федераль законнарда каралган очракларда хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсе төзегәндә чикләүләрне үтәүләрен;»;

г) «п» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«п) үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрнең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыруны, шулай ук гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру өчен әлеге белешмәләрне бирүне тәэмин итүдә катнашу:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан;».

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» 2023 елның 19 июнендәге 411 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында нигезләмәнең 7 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) кырык сигезенче һәм кырык тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылган гражданнар тарафыннан тапшырылган керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне, әлеге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрен кабул итү, анализлау һәм тикшерү, шулай ук әлеге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренең коррупциягә каршы көрәшү максатларында кертелгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвен тикшерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә дәүләт хезмәте биләгән гражданнарның дәүләт хезмәтеннән азат ителгәннән соң федераль законнарда каралган очракларда хезмәт шартнамәсен һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсен үтәүләре турында белешмәләрне анализлау;»;

б) алтмыш җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 12 май
№ 355